| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.04.2019 ел Баулы шәһәре № 104

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булган муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре, үзәкләштерелгән бухгалтерия һәм хисаплылык бүлекләре белгечләре хезмәтенә түләү оештыру һәм шартлары турында

Татарстан Республикасы Финанслар Министрлыгының 2019 елның 1 апреленнән Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре (бүлекләре) булган муниципаль казна учреждениеләре җитәкчеләре, белгечләре, үзәкләштерелгән бухгалтерия һәм хисаплылык бүлекләре белгечләре хезмәтенә түләүнең яңа системасы кертелүе турындагы 2019 елның 18 апрелендәге 03-16/2920 санлы хаты нигезендә, Баулы муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымтадагы түбәндәгеләрне расларга:

Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Мәгариф бүлегенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризм үсеше бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтер исәбе һәм хисап бүлеге җитәкчеләре һәм

белгечләре хезмәтенә түләү оештыру һәм шартлары турында нигезләмәне,

2. Хезмәткәрләрнең әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәт хакы күләме, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме сакланганда һәм алар тарафыннан шул ук квалификация үтәлгәндә, аларга 2019 елның 31 мартына түләнә торган хезмәт хакы күләменнән ким була алмый.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Җирле үзидарә органнарының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Мәгариф бүлегенең үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль казна учреждениесе, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризм үсеше бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең бухгалтер исәбе һәм хисап бүлеге җитәкчеләре һәм белгечләре вазыйфалары атамасын әлеге карардагыга туры китерүне тәэмин итәргә тиеш;

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров